БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«04» 07 2026 ел

**КАРАР**
№ 212

Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Балтач районы прокуратурасының 2026 елның 10 июнендәге 02-08-02-2026/Прдп228-26-20920011 номерлы протестын карап, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2026 елның 12 февралендәге 82 номерлы карары белән расланган муниципаль милектә булган җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 18 пунктның 14 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән мондый җир кишәрлегеннән файдалану максаты җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалануның бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрына кертелгән төп төренә яисә җир кишәрлегеннән файдалануның территориядән файдалану Регламентында билгеләнгән рөхсәт ителгән төрләренә туры килми. Әгәр җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максат өчен мондый җир кишәрлеге җир категориясенә һәм рөхсәт ителгән файдалану төренә бәйсез рәвештә файдаланылырга мөмкин булса, шулай ук линия объекты территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә урнаштырылган очракта әлеге пунктча нигезләмәләре кулланылмый;»;

1.2. 18 пунктның 17 пунктчасында «территориаль планлаштыру документлары белән һәм (яисә) расланган» сүзләрен «расланган» сүзенә алмаштырырга, «җир кишәрлеген бирү турында гариза белән мондый җир кишәрлегендә урнашкан биналарның, корылмаларның, алардагы урыннарның хокук иясе, төгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе, мондый җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә.»;

1.3. 18 пунктның 18 пунктчасында «җир кишәрлеген бирү турында

корылмаларның, алардагы урыннарның хокук иясе, тәгәлләнмәгән төзелеш объекты милекчесе, мондый җир кишәрлеге даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә»;

1.4. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Бердәм портал, Республика порталы аша Башкарма комитетка, КФҮга мөрәҗәгать иткән очракта хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 15 эш көне тәшкил итә. Вәкаләтле орган кергән гаризаны карый, шушы регламентның 18 пунктында каралган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә һәм күрсәтелгән карау һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге гамәлләрнең берсен башкара:

1) сату-алу шартнамәсе, җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе яисә җир кишәрлегеннән түләүсез файдалану шартнамәсе проектларын өч нөсхәдә әзерли һәм аларны имзалый, шулай ук, сорала торган җир кишәрлеген төзү яисә аның чикләрен тәгәлләштерү таләп ителмәгән очракта, күрсәтелгән шартнамәләрнең проектларын мөрәҗәгать итүчегә имзалау өчен җибәрә;

2) сорала торган җир кишәрлеген төзү яисә аның чикләрен тәгәлләштерү таләп ителмәгән очракта, җир кишәрлеген милеккә түләүсез яисә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга бирү турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә;

3) шушы регламентның 18 пунктында каралган нигезләр булган очракта, җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрә. Бирелгән карарда баш тартуның барлык нигезләре күрсәтелергә тиеш.».

1.5. 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән исәпләнә башлый.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе — А.Ф.Хәйретдинов